| | |
|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЦ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

| | |
|---|---|
| ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР |
| 21.10.2020 | 1406-п |

2021-2025 елларга Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының жирле әһәмияттәге гомуми файдаланудa булган автомобиль юлларын төзекләндерү һәм норматив хәлгә китерү буенча муниципаль программаны раслау турында

“Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының муниципаль юл фондын төзү турында” 2013 елның 9 октябрендәге 216 номерлы Саба муниципаль районы Советы карары нигезендә һәм Саба муниципаль районының юл фонды акчаларыннан файдалану максатларында, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2021-2025 елларга Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының жирле әһәмияттәге гомуми файдаланудa булган автомобиль юлларын тозекләндерү һәм норматив хәлгә китерү буенча муниципаль программаны расларга.
2. Саба муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлегенә 2021-2025 елларга Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының жирле әһәмияттәге гомуми файдаланудa булган автомобиль юлларын тозекләндерү һәм норматив хәлгә китерү буенча муниципаль программасының тормышка ашуын тәэмин итәргә.
3. Әлеге карарны “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында һәм Саба муниципаль районының http://saby.tatarstan.ru рәсми сайтында бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Саба муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге начальнигы И.Б. Таиповка йөкләргә.

Саба муниципаль районы
Башкарма комитеты Житәкчесе
вазыйфаларын башкаручы М.Р.Ишниязов

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 21 октябрендәге 1406-п номерлы карары белән
РАСЛАНГАН

**2021-2025 елларга Татарстан Республикасы Саба муниципаль районыныц җирле әһәмияттәге гомуми файдалануда булган автомобиль юлларын тозекләндерү һәм норматив хәлгә китерү буенча Муниципаль программа**

**Программа паспорты**

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | 2021-2025 елларга Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының җирле әһәмияттәге гомуми файдалануда булган автомобиль юлларын төзекләндерү һәм норматив хәлгә китерү буенча муниципаль программа (алга таба - Программа) |
| Программаны эшләүчеләр | Саба муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге |
| Программаның максатлары һәм чаралары | Программаның максаты - халыкка транспорт хезмәте күрсәтүнең сыйфатын күтәрү, Саба муниципаль районы торак пунктларының урам-юл инфраструктурасы эшчәнлеген җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын норматив хәлгә китерү юлы белән тәэмин итү. |
| Программаның бурычлары | Саба муниципаль районының җирле әһәмияттәге гомуми файдалануда булган автомобиль юлларын төзекләндерү һәм норматив хәлгә китерү планын эшләргә |
| Программаны гамәлгә ашыру срогы | 2021-2025 еллар |
| Ярдәмче программалар исемлеге | Ярдәмче программалар каралмаган |
| Программаны финанслау күләмнәре | 2021-2025 елларда Программаны Саба муниципаль районы бюджеты акчалары хисабына финанслауның гомуми күләме 80 500,000 мең сум тәшкил итәчәк, шул исәптән:<br>2021 ел - 15 400,000 мең сум;<br>2022 ел - 16 200,000 мең сум;<br>2023 ел - 16 300,000 мең сум;<br>2024 ел - 16 300,000 мең сум; |

| | |
|---|---|
| | 2025 ел - 16 300,000 мең сум.<br>Программаны финанслау күләмнәре фаразлану характерына ия һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Советының чираттагы финанс елына (чираттагы финанс елына һәм план чорына)Саба муниципаль районы бюджеты турындагы карары нигезендә төгәлләштереләчәк.<br>Саклланган акчаларның калган өлешен ел саен юл хәрәкәте куркынычсызлыгы чараларына җибәрергә. |
| Программаны гамәлгә ашыруның төп нәтиҗәләре | Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы торак пунктларының урам-юл инфраструктурасының тулы канлы эшчәнлеге нигезендә район халкының тормыш дәрәҗәсен күтәрү.<br>Программаның нәтиҗәлелеге Программаның бүлекчәләрендә билгеләнгән максатчан күрсәткечләргә ирешү дәрәҗәсе буенча бәяләнә. |

## 1. Саба муниципаль районы торак пунктларының урам-юл инфраструктурасына характеристика.

2021-2025 елларга Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзекләндерү һәм норматив хәлгә китерү буенча муниципаль программа (алга таба - Программа) Саба муниципаль районы Советының “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының муниципаль юл фондын төзү турында” 2013 елның 9 октябрендәге 216 номерлы карары нигезендә эшләнгән.

Саба муниципаль районы 1930 елда төзелгән, Татарстанның төньягында Кама алды икътисадый зонасының үзәк өлешендә урнашкан. Районның мәйданы 1098 кв.км, ул Татарстан Республикасының гомуми мәйданының 1,62 % ын тәшкил итә. Унтугыз авыл һәм бер шәһәр җирлеген 67 торак пункт берләштерә, халык саны 2016 елның 1 гыйнварына 31736 кеше тәшкил итә.

Район территориясе Мишә елгасы бассейнының өске өлешен алып тора. Нигездә, бу - елга үзәннәре белән киң һәм сөзәк түтәлләргә бүленгән калкулыклы тигезлек. Алар, үз чиратында, кечерәк елгаларның озын чокырлары һәм вак үзәннәре белән вак икенчел калкулыкларга һәм сөзәк калкулыкларга бүлгәләнә.

Район үзәге - Б.Сабасы шәһәр тибындагы бистәсе, республикабыз башкаласы - Казан шәһәреннән 98 чакрым ераклыкта, Шәмәрдән тимер юл станциясеннән 22 чакрым ераклыкта, Нократ Аланыннан 60 чакрым ераклыкта урнашкан.

Саба районы, Татар АССР составында административ-территориаль берәмлек буларак, 1930 елның 10 августында Россия Үзәк Башкарма комитеты карары белән төзелгән.

“Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы” муниципаль берәмлеге 2005 елның 31 гыйнварындагы 38-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә төзелгән.

2020 елның 11 февраленә җирле әһәмияттәге гомуми файдалануда булган автомобиль юлларының озынлыгы.

1 таблица

| 2020 елнын 11 февраленә җирле әһәмияттәге автомобиль юллары | Барлы гы (км) | Озынлыгы (км), шул исәптән | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | ц/б | а/б | вак таш, гравий | грунт |
| Җирлекләрнең урам-юл челтәре | 322,44 | 0,13 | 131,12 | 104,39 | 86,77 |
| Норматив таләпләргә җавап бирми торган җирле әһәмияттәге автомобиль юлларыныц озынлыгы | 86,77 км. - бу гомуми озынлыкның 26,91 % ын тәшкил итә. | | | | |

Җирле әһәмияттәге гомуми файдалануда булган автомобиль юлларына хезмәт күрсәтүче оешмалар: “Саба ТКХ МПП” ААҖ, “Саба районының Шәмәрдән ТКХ МПП” ААҖ, “Рамазан” ҖЧҖ.

Автотранспорт предприятиеләре: “Яшен” ҖЧҖ.

Мәгариф учреждениеләре укучыларын йөртүче автотранспорт предприятиесе: “Яшен” ЖЧЖ. Мәктәп маршрутлары - 37, Мәктәп автобуслары - 24 бер. Гомуми белем бирү мәктәпләре саны - 21, шул исәптән урта мәктәпләр - 15, төп мәктәпләр - 6.

**2016-2020 елларда Саба муниципаль районының җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын тозекләндерү һәм норматив хәлгә китерү**

2 таблица

| Өслек тибы | 2016 | | 2017 | | 2018 | | 2019 | | 2020 | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | а/б | вак таш | а/б | вак таш | а/б | вак таш | а/б | вак таш | а/б | вак таш |
| Төзекләндерү һәм норматив хәлгә китерү (км) | 4,81 | 5,36 | 3,92 | 4,69 | 3,66 | 3,94 | 3,84 | 4,34 | 3,85 | 3,80 |
| | 10,17 | | 8,61 | | 7,60 | | 8,18 | | 7,65 | |

## 2. Саба муниципаль районының юл инфраструктурасы сыйфатын үстерүнеп институциональ проблемалары

Икътисадый киңлекнең состав өлеше булган юл тармагы икътисадны үстерүгә, шәһәр җирлегенең, авыл җирлекләренең һәм аерым торак пунктларның социаль өлкәсен яхшыртуга актив йогынты ясый һәм транспорт-коммуникация системасын үстерүдә мөһим роль уйный. Районның бөтен икътисады кебек үк, юл тармагы да даими үсә. Әмма юл челтәрен үстерү темплары бүгенге заман таләпләренә җавап бирми. Автомобильләшү һәм юл челтәрен үстерү арасындагы аерма бүген кискен характерга ия булды.

Саба муниципаль районы юл инфраструктурасының сыйфатын үстерү проблемалары булып түбәндәгеләр тора:

1. Үз-үзен тәэмин итүнең житәрлек дәрәҗәдә булмавы (икътисадый, финанс, социаль).

2. Юл хуҗалыгы объектларының техник паспортлары һәм аларны әзерләүгә финанс чаралары булмау.

3. Җирле бюджетлар керемнәренең түбән дәрәҗәсе һәм юл эшчәнлеген җитәрлек күләмдә финансламау.

Әлеге Программа югарыда әйтелгән институциональ проблемаларны хәл итүгә юнәлдерелгән.

## 3. Саба муниципаль районы юл инфраструктурасыныц сыйфатын күтәрү олкәсендәге проблемаларны хәл итү буенча топ бурычлар

– Автомобиль юлларының гамәлдәге юл челтәрен һәм аларда ясалма корылмаларны саклау һәм торгызу.

– Автомобиль юлларыннан файдаланучыларның ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен кирәкле дәрәҗәдә аларның транспорт-эксплуатация күрсәткечләрен тәэмин итү.

– Төзекләндерү һәм яхшы хәлдә тоту буенча эшләрне вакытында һәм сыйфатлы башкару.

## 4. 2021-2025 елларга Татарстан Республикасы Саба муниципаль районынын җирле әһәмияттәге гомуми файдаланууда булган автомобиль юлларын төзекләндерү һәм норматив хәлгә китерү буенча муниципаль программаның топ чаралары

3 таблица

| № п\п | Чаралар атамасы | Башкаручылар (килешү буенча) | Финанслау күләме һәм чыганаклары (мен сум) | Үтәү срогы |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Смета документларын эшләү | Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының җирлекләр башлыклары | Саба муниципаль районы бюджеты, Барлыгы 80 500,000, шул исәптән:<br>2021 ел - 15 400,000;<br>2022 ел - 16 200,000;<br>2023 ел - 16 300,000;<br>2024 ел - 16 300,000;<br>2025 ел - 16 300,000, әлеге Программаның 4 таблицасында күрсәтелгән финанс чараларын бүлү нигезендә | Агымдагы елның апрель - март айлары |
| 2 | Смета документларын тикшерү | “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының бердәм заказчысы хезмәте” МУП, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы Казначылык департаментының Саба районы территориаль бүлеге | | тикшерүгә бирелгән көннән башлап 1 атна дәвамында |
| 3 | Төзекләндерү эшләрен башкару | Ачык аукцион нәтиҗәләре буенча электрон сатуларда откан подрядчы оешма | | контрактта күрсәтелгән сроклар |
| 4 | Башкарыла торган эшләрнен сыйфатын техник күзәтү һәм тикшереп тору | “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башкарма комитетының бердәм заказчысы хезмәте” МУП | | эшләр эшләнү дәвамында |
| 5 | Башкарылган эшләрне кабул итү һәм объектны файдалануга тапшыру | Заказ бирүче - (объектның баланс тотучысы),<br>Заказ бирүче-төзүче – “ТР Саба муниципаль районы Башкарма комитетынын бердәм заказчысы хезмәте” МУП | | төзекләндерү эшләрен төгәлләү буенча |

**5. 2021-2025 елларда җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзекләндерүгә юл фондының финанс чараларын бүлү**

4 таблица

| № | Җирлекләр исеме | Акчаларны еллар буенча бүлү (мен сум) | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2021 | 2022 | 2023 | 2024 | 2025 |
| 1. | Саба шәһәр җирлеге | | | 3 260,000 | | |
| 2. | Арташ авыл җирлеге | 3 080,000 | | | 3 260,000 | |
| 3. | Олы Кибәче авыл җирлеге | | 3 240,000 | | | 3 260,000 |
| 4. | Олы Нырты авыл җирлеге | 3 080,000 | | | | |
| 5. | Олы Шыңар авыл җирлеге | | 3 240,000 | | | 3 260,000 |
| 6. | Корсабаш авыл җирлеге | 3 080,000 | | | | |
| 7. | Югары Симет авыл җирлеге | | 3 240,000 | | | 3 260,000 |
| 8. | Явлаштау авыл җирлеге | 3 080,000 | | | | |
| 9. | Эзмә авыл җирлеге | | 3 240,000 | | | |
| 10. | Иштуган авыл җирлеге | 3 080,000 | | | | |
| 11. | Килдебәк авыл җирлеге | | 3 240,000 | | | 3 260,000 |
| 12. | Түбән Шытсу авыл җирлеге | | | 3 260,000 | | |
| 13. | Мишә авыл җирлеге | | | | 3 260,000 | |
| 14. | Мичән авыл җирлеге | | | 3 260,000 | | |
| 15. | Сатыш авыл җирлеге | | | | 3 260,000 | |
| 16. | Иске Икшермә авыл җирлеге | | | 3 260,000 | | |
| 17. | Тимершык авыл җирлеге | | | | 3 260,000 | |
| 18. | Шекше авыл җирлеге | | | 3 260,000 | | |
| 19. | Юлбат авыл җирлеге | | | | 3 260,000 | |
| 20. | Шәмәрдән авыл җирлеге | | | | | 3 260,000 |
| | **БАРЛЫГЫ:** | **15 400,000** | **16 200,000** | **16 300,000** | **16 300,000** | **16 300,000** |